КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 апрель г.Казань № 525

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 12 апрель, 288 нче карары белән расланган Югары һөнәр белеме бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерының яраштыру советы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 12 апрель, 288 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 июнь, 516 нчы; 2014 ел, 18 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1002 нче; 2021 ел, 15 июнь, 460 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Югары һөнәр белеме бирүче «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» федераль дәүләт бюджет белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерының яраштыру советы турындагы нигезләмәгә, 1.1 пункттагы «, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча 2009 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планы турында» 2009 ел, 2 февраль, 63 нче карары» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин